ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» гыйнварыннан № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9678,63 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https:///pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 01 февраленнән гамәлдә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «___» гыйнварыннан
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булучының законлы вәкилләре булган вафат булучыларны (һәлак булганнарны) җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3423,23 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1467,21 |
| 4. Зиратта җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4788,19 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «__» гыйнварыннан
___ номерлы карарына
2 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булучының законлы вәкилләре булмаган вафат булучыларны (һәлак булганнарны) җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү (кәфенләү) | 550,21 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 2873,02 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1467,21 |
| 5. Зиратта җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4788,19 |
| Барлыгы | 9678,63 |